СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

04.02.2021 с. Старое Русское Маматкозино 5-34

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне юкка чыгару турында.

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019нчы елның 16нчы декабреннән 432-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советының 2017нче елның 30нчы сентябрендәге 29-136нчы номерлы карары белән расланган Нигезләмәне гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В. В. Никитушкин